**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 17 декабрендәге 5211 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 2 июлендәге 3783 номерлы**
**«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә**
**ярминкә операторын билгеләү буенча конкурс үткәрү турындагы**
**нигезләмәне раслау турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә эшчәнлекне дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре территориясендә ярминкәләр эшчәнлеген (аларда эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне) оештыруны тәртипкә салу максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 2 июлендәге 3783 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ярминкә операторын билгеләү буенча конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 26 июлендәге 2713 номерлы, 2020 елның 29 октябрендәге 3052 номерлы, 2021 елның 16 апрелендәге 915 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтаның 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2. Конкурсны уздыру буенча вәкаләтле орган – 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мислававский урамы, 8 йорт адресы буенча урнашкан «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба –

Вәкаләтле орган)»;

1.2. 1 номерлы кушымтаның 1.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- ярминкә мәйданчыгы – ярминкә үткәрелә торган территория»;

1.3. 1 номерлы кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2.1.1 пунктны өстәргә:

«2.1.1. Оператор ярминкә мәйданчыгын төзекләндерү элементларының һәм корылмаларының сакланышын һәм төзеклеген тәэмин итәргә тиеш»;

1.4. 1 номерлы кушымтаның 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.4. Вәкаләтле орган, гаризалар һәм документлар кабул итү датасына кадәр кимендә 30 календарь көн кала, Конкурс уздыру турында хәбәрнамәне, шулай ук конкурс документларын «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгара, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм җирле үзидарә органнарының рәсми порталындагы үз сәхифәсендә www.kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/kpr (алга таба – рәсми сәхифә) урнаштыра. Анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Дәгъвачылардан документларны кабул итү вакыты һәм урыны;

- Конкурсны уздыру датасы, вакыты һәм урыны;

- ярминкә уздыру күздә тотыла торган урамнарның, юлларның, транспортта узу урыннарының, башка ориентирларның адреслы тамгасы, чикләре;

- Конкурста катнашу өчен әлеге нигезләмәнең 2.7 пунктында каралган кирәкле документлар исемлеге»;

1.5. 3 номерлы кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2.3.19 пунктны өстәргә:

«2.3.19. исемлек (шартнамәгә кушымта) нигезендә ярминкә мәйданчыгының төзекләндерү элементларының һәм корылмаларының сакланышын һәм төзеклеген тәэмин итәргә, шул исәптән зыян килгән элементларны (корылмаларны) ремонтлау, торгызу һәм алмаштыру эшләрен башкарырга»;

1.6. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ярминкә оештыру һәм уздыру турындагы шартнамәнең кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 пунктлар өстәргә:

«5. Ярминкәдә сәүдә урыны бирү турында төзелгән һәм ___________ хисап чорында гамәлдә булган шартнамәләр турында мәгълүматлар (шартнамәләр күчермәләре).

6. Ярминкәдә катнашучылардан түбәндәге шартнамәләр буенча алына торган сәүдә урыны өчен түләү күләме: ________».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**